ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Битлянгур авылында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

14 ноябрь, 2024 ел №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Битлянгур авылында гражданнар җыены карар чыгарды:

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Кукмара районы Түбән Өскебаш авыл җирлегенең Битлянгур авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән ,1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан), 85 яшькә житкән һәм аннан да өлкәнрәк кешеләрдән, 4 баласы һәм аннан да күбрәк балалары булган гаиләләрдән,18 яшькә кадәрге баланы тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан , җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалардан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су коймасын тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау; (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү; артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру; материаллар сатып алу, суүткәргеч челтәрен ремонтлау, су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау, су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су җыю башняларын тоту буенча башка эшләр; Битлянгур авылындагы су манарасын коймалар белән әйләндереп алу (материал сатып алу, эшләр өчен түләү); проект-смета документациясе һәм шартнамә буенча түләү

2)янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын сүндерү савытлары һәм кирәкле җиһазлар, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

3)торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - Битлянгур авылының урам-юл челтәренә вак таш салу, ремонтлау, карап тоту,вак таш сатып алу,юлларны кардан чистарту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

4)торак пункт территориясен төзекләндерү (Битлянгур авылы территориясен төзекләндерү, проект-смета документлары, эш өчен шартнамә буенча түләү, территорияне төзекләндерү буенча башка эш төрләре, ,; "Беларус 82.1. тракторын карап тоту, тракторга ягулык материаллары һәм запас частьләр сатып алу); агач (тополь, юкә һ.б.) кисү һәм чүп-чар чыгару, проект-смета документлары, шартнамә буенча түләү;

5)жир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр)( Битлянгур авылы чишмәләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, чишмәләрне төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эшләр) ;

6)тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Битлянгур авылында урам яктыртуны көйләү өчен, урам яктырткычлары һәм махсус җиһазлар сатып алу, ремонтлау);

7)Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм алар янәшәсендәге территорияне төзекләндерү; (ВОВ катнашучылары хөрмәтенә обелиск урнаштыру; янәшәсендәге территорияне карап тоту һәм төзекләндерү, проект-смета документациясен ясау һәм шартнамә буенча түләү)

3. Әлеге карарны Түбән Өскебаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында kukmor.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Өскебаш авыл җирлеге
башлыгы: Н.М.Мөхәммәтжанов

ОГРН 1061675011188
ИНН 1623008539